ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.17,
с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 17йорт,
Акбаш авылы, 423958

Тел.:(85593) 4-14-34, факс:4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

04 декабрь 2023 ел №21

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Акбаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 21 декабрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында»гы 17 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160¹ маддәсендәге 3² пунктының өченче абзацына ярашлы рәвештә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге бюджеты керемнәре баш администраторы вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге бюджеты администраторы вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына түбәндәге бюджет классификациясе кодлары буенча беркетергә:

| Бюджет классификациясе коды | | Бюджет керемнәре баш администраторының исеме<br><br>(бюджет керемнәренең төр (төркемчәсе) коды исеме |
|---|---|---|
| Керем администраторы | Бюджет кеременең төре (төркемчәсе) | |

| 803 Ютазы муниципаль районы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы | | |
|---|---|---|
| 803 | 1 14 06325 10 0000 430 | Мондый җир кишәрлекләрен һәм авыл җирлекләре милкендәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектәге җир кишәрлекләренең мәйданын арттыру өчен түләү |

2.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең рәсми Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://jutaza.tatarstan.ru/) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар, 2023 елның 1 декабреннән башлап, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджет (2023 елга) кулланыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы И.Р.Сәхибуллина